ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы,
422581

Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

30.11.2024 № 4

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авылы җирлегенең Куралово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Куралово авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?" - Куралово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2024 елның 30 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 835 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 427 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 426 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Куралово авылы территориясендә теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Куралово авылында 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?" - Куралово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Е. Тарасов